**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлегенең Бик-Үти авылында гражданнар җыены карары**

**25 октябрь 2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлегенең Бик-Үти авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Бик-Үти авыл җирлегенең Бик-Үти авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

Бик-Үти торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Бик-Үти авыл җирлегенең Бик-Үти авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Бик-Үти авыл җирлеге башлыгы _________ Р.З.Җәлялетдинов

Халык җыены секретаре _________ Р.С.Гыйззәтова